ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2017 ел № 21/13

Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында
Нигезнамәне раслау хакында

Россия Федерациясе гражданнарын һәм чит ил гражданнарын, шулай ук оешма коллективларын, аларның оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, шәхси эшмәкәрләрне шәһәр бүләкләре белән бүләкләү тәртибен камилләштерү максатларыннан, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.
2. Гамәлдән чыккан дип танырга:
1) Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәне раслау турында» 25/23 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2007 ел, 26 октябрь, 205-207 саннарында бастырылган;
2) Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/23 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәнең 18 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 31/9 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 25 апрель, 82-84 саннарында бастырылган;
3) Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/23 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 35/13 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 26 ноябрь, 228-229 саннарында бастырылган;
4) Шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/23 санлы Карары белән расланган Яр

Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 18/16 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 25 апрель, 32 санында бастырылган;

5) Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы «Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/23 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 25/20 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 16 июнь, 46 санында бастырылган.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының 21/13
санлы Карарына кушымта
15 декабрь, 2017 ел

Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында
НИГЕЗНАМӘ

1. Яр Чаллы шәһәре бүләкләре шәһәр үсеше һәм халыкның иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертеп, төзелеш, икътисад, фән, мәдәният һәм мәгариф, законлылыкны ныгыту, сәламәтлек һәм кеше тормыщын саклау, гражданнарның хокукларын саклау, спорт үсеше, тәрбия эше, актив иганәчелек һәм башка өлкәләрдә ирешелгән казанышлар өчен кызыксындыру формасы булып тора.

2. Яр Чаллы шәһәре бүләкләре (алга таба – шәһәр Бүләкләре):

1) «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме;

2) «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе;

3) Яр Чаллы шәһәре Хакименең Мактау грамотасы;

4) Яр Чаллы шәһәре Хакименең Рәхмәт хаты;

5) Яр Чаллы шәһәре Хакименең Рәхмәте.

3. Шәһәр Бүләкләре белән гражданнар, оешмалар, Шәһәр Советы Карарлары белән билгеләнгән вазифаи затлар, сайлап куелган вазифаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр бүләкләнә.

4. Шәһәр Бүләкләре белән бүләкләнүгә тәкъдим иткәндә бүләкнең төре бүләкләр турындагы нигезнамә нигезендә бүләкләнүченең шәхси казанышлары характеры һәм дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

Башка шәһәр Бүләге белән бүләкләү алдагы бүләкләнүдән соң өч елдан да иртә башкарылмый.

5. Бер исемдәге шәһәр Бүләкләре белән берничә тапкыр бүләкләү рөхсәт ителми.

6. Бүләкләү турында тәкъдим белән белән барлык милек формасындагы оешма, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре мөрәҗәгать итә ала.

7. Бүләкләү турында тәкъдим шәһәр Хакиме каравына  тапшырыла.

8. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме һәм «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнүгә тәкъдим ителүче һәр затка, билгеләнгән тәртиптә, бүләкләү кәгазе тутырыла, ул бүләкләү турында юллама белән бергә бирелә (әлеге нигезнамәнең кушымтасында каралган тәртиптә).

9. Шәһәр Бүләкләре белән бүләкләү нигезләре һәм шартлары, бүләкләү юлламасы белән бергә тапшырылучы документлар һәм мәгълүматлар исемлеге шәһәр Хакименең хокукый актлары белән билгеләнә.

10. Материалларны иҗтимагый бәяләү һәм бүләкләүне объектив башкару максатыннан, шәһәр Хакиме «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме һәм «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе белән

бүләкләнүгә тәкъдим ителүчеләрнең документларын карау өчен Комиссия җыя (алга таба – Комиссия). Комиссиянең эш тәртибе шәһәр Хакиме тарафыннан расланган комиссия турында нигезнамә нигезендә башкарыла.

11. Шәһәр Бүләкләрен тапшыруны Шәһәр Хакиме кушуы буенча һәм аның исеменнән башкара алаларр:

1) Башкарма комитет Җитәкчесе;

2) муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары.

Шәһәр Хакиме шәһәр Бүләкләрен тапшыруны җирле узидарәнең башка вазифаи затларына да йөкләргә хокуклы.

12. Шәһәр бүләкләре һәм аларның документларын тапшыру, шәһәр Хакименең бүләкләү турында хокукый акты чыккан көннән алып ике айдан да соңга калмыйча, тантаналы шартларда башкарыла.

13. Бүләкләү турында тәкъдим бүләкләнүче исән вакытта каралган яйсә бүләкләү батырлык кылу, кыюлык һәм каһарманлык күрсәтү белән бәйле булган очракта, шәһәр Бүләкләре белән бүләкләү кеше вафат булганнан соң да гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бүләк төрен Яр Чаллы шәһәр Хакиме билгели. Бүләкләнүчеләр вафат булган очракта, аларга тиешле шәһәр Бүләкләре һәм бүләк документлары варисларына тапшырыла.

14. Шәһәр Бүләген югалткан очракта, гариза белән мөрәҗәгать нигезендә, бүләкләү фактын раслаучы документ күчермәсе бирелергә мөмкин. Документ күчермәсен Башкарма комитетның вәкаләтле органы тапшыра.

Бүләк дубликатлары тапшырылмый.

15. Шәһәр бүләкләре белән бүләкләнүчеләрнең хисабы Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан алып барыла.

«Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме һәм «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнүгә тәкъдим ителүчеләргә шәхси эшләр ачыла. Шәхси эшләргә бүләкләү кәгазе, бүләкләү өчен юллама, фоторәсемнәр һәм башка документлар теркәлә.

16. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре Мактау грамоталарын, Рәхмәт хатларын, Дипломнарны гамәлгә куеп, алар белән бергә, әлеге нигезнамәнең 18 пунктында каралган тәртиптә, кызыксындыру бүләкләре дә тапшыра алалар.

17. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары Мактау грамоталары һәм территориаль органнары Рәхмәт хатлары гамәлгә куела .

18. Шәһәр Бүләкләре белән бергә түбәндәге кызыксындыру бүләкләре бирелергә мөмкин:

1) кыйммәтле бүләкләр;

2) бер тапкыр бирелүче акчалата түләү

Кыйммәтле бүләк һәм акчалата түләү күләме җирле үзидарә органнары сметасы белән билгеләнә.

19. Мәгариф, сәнгать, спорт өлкәсендә, иҗтимагый эшчәнлектә аеруча талантлы һәм перспективалы балалар һәм яшьләрне ачыклау, аларның талантын һәм тырышлыгына бәя бирү, сәләтле балалар һәм яшьләргә матди ярдәм күрсәтү, балалар һәм үсмерләр иҗатының бар төрен дә стимуллаштыру

максатыннан шәһәр Хакиме тарафыннан исемле стипендияләр гамәлгә куелырга мөмкин.

Муниципаль учреждение хезмәткәрләренең һөнәри үсешен стимуллаштыру максатыннан шәһәр Хакиме тарафыннан премияләр гамәлгә куелырга мөмкин.

Сәламәт тормыш алып бару рәвешен пропагандалау, физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнү, физик хәзерлек дәрәҗәсен һәм спорт осталыгын арттыру максатыннан шәһәр Хакименең күчмә Кубоклары гамәлгә куелырга мөмкин.

Исемле стипендияләр, премияләр, Кубоклар бирү Хаким тарафыннан, Шәһәр Советы раслаган күләмдә һәм тәртиптә, гамәлгә куелырга мөмкин.

20. Шәһәр Бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнең нигезсез булуы яйсә тәкъдим итү документларында дөрес булмаган мәгълүматлар күрсәтү очраклары ачыкланса, бүләкләү турында карар аны кабул иткән орган (вазифаи зат) тарафыннан гамәлгә чыккан дип таныла.

Бүләкләү хакындагы карарны гамәлдән чыккан дип тану турындагы хокукый акт бүләкләү турында кабул ителгән карарны үз эченә алган хокукый акт төрендә башкарыла.

21. Шәһәр Бүләге белән бүләкләү турында карар гамәлдән чыгарылган очракта, бүләк атрибутлары һәм таныклыгы Башкарма комитетның вәкаләтле органына кайтарылырга тиеш.

22. Әлеге Нигезнамәне тормышка ашыру өчен финанс чыгымнары Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан алына.